
Яшьлек
Минзәлә шәһәре гимназиясе
Киләчәкнең башы - бүгенгедә
1998
Сентябрь, 2017 ел.
Белем көне белән!
Җәең ничек үтте?
Атна шәхесе -
Гөлназ апа!

# Белем көне




Яңгырыйдыр һәр төбәктә
Көмеш кыңгырау чыңы.
Мәктәпләргә рәхим ит син,
Өр-яңа уку елы !

Белем көне - ул чәчәкләр һәм ак тасмалар бәйрәме. Бу көнне һәр укучы, чәчәк бәйләме тотып, уку йортына ашыга. Күпләр бу бәйрәмне "Беренче кыңгырау" бәйрәме дип тә йөртәләр, чөнки нәкъ менә бу көнне мәктәп балалар бакчасыннан килгән "яңа" укучыларын каршы ала. Ап-ак тасма бәйләгән, кулларына кечкенә портфель тоткан укучылар беренче тапкыр белем йорты бусагасын атлап керә, беренче укытучылары белән очраша, беренче кыңгырау тавышын ишетә.

1нче сентябрь рәсми рәвештә "Белем көне" дип беренче тапкыр 1984 нче елда игълан ителә. Бу көнне һәр укучы бәйрәм итә. Шулай да "Белем бәйрәме"н беренче сыйныфка баручылар аерым бер дулкынлану белән көтеп алалар бит.

Гимназиябездә дә “Белем көне” беркемне дә битараф калдырмады! Укучы һәм укытучыларыбызны, килгән кунакларны кем генә каршы алмады ул көнне?! Безгә кунакка үзебезнең төлке һәм аю “Фиксик” дусларыбызны ияртеп алып килсәләр, ерак Америкада урнашкан “Диснейленд” тан Микки Маус һәм Миньоннар да ашыга-ашыга килгәннәр иде. Җыр-бию, уен-көлке бер минутка да өзелеп тормаган бу бәйрәм укучыларыбызда бары тик уңай тәэсирләр генә калдырды!

Әйдәгез әле, шуларның берничәсе белән танышып үтик:



**Сәлимгәрәева Әмирә, (1нче сыйныф)**

- Сәлам, Әмирә!
- Сәлам!
- Күптән түгел генә булган синең иң мөһим бәйрәмнәреңнең берсе - “Беренче кыңгырау” бәйрәме узды. Бу бәйрәм синең өчен нәрсәсе белән исеңдә калды?
- Микки Мауснын биюе миңа бик ошады, һәм мин аны әле һаман да өйдә биеп йөрим.

**Дәүләтова Чулпан, (11нче сыйныф)**

- Сәлам,Чулпан!
- Сәлам!
- Син - 11нче сыйныф укучысы. “Белем бәйрәме”нең оештыручысы буларак, бу бәйрәм синдә нинди тәэсирләр калдырды? - Соңгы елны укыганга күрә, белем көне әлбәттә, минем күңелемдә якты хатирә булып, бик озакка калачак.







Низамова Сөмбел

Атна шәхесе- Гөлназ апа!

# Атна шәхесе- Гөлназ апа!



Бу чыгарылышның “атна шәхесе” - безнең иң яраткан, иң хөрмәтле директорыбыз Гөлназ апа Сәмигулла кызы. Шушы уңайдан без аны яңа гына билгеләп үтелгән укытучылар көне белән тәбриклибез. Аңа ныклы сәламәтлек, эшендә зу-у-р уңышлар телибез!

**Туган көне: 20.06.77**
**Яраткан фильмы: “Красотки”**
**Яраткан китабы: Анна Каренина**
**Яраткан ризыгы: бәлеш.**

**-Исәнмесез, Гөлназ апа!**

- Хәерле көн, Айзилә.

- **Сезнең кумирыгыз бармы?**

- Хм...(озак уйлый, елмая) Кумир, кумир... юктыр.

- **Сез үзегезне уңышлы кеше дип санныйсызмы?**

- Әлбәттә.

- **Әгәр “вакыт машинасы”на утырып, үткәнгә кире кайтып булса, Сез ни дә булса үзгәртер идегезме?**

- Болай гына әйтә дә алмыйм инде, юк дип уйлыйм.

- **Бик зур рәхмәт, Гөлназ апа. Ә шулай да күптәннән күңелегездә йөрткән берәр соравыгыз юкмы? Тик әлегә андый сорауны бирергә форсаты гына чыкмагандыр?**

**-** (елмая) Юк, андый соравым юк.

**- Без хәзер Instagram’да бар, ишеткән идегезме?**

- Бик күптән ишеттем, ләкин мин үзем бу интернет челтәрдә әлегә юк.

- **Сез бит әле 3 бала әнисе дә, вакытыгызны ничек җиткерәсез?**

**-** Мөгаен, көн тәртибем ачык билгеле булгангадыр.

- **Балаларыгыз берәр нинди өстәмә белем бирү түгәрәкләренә йөриләрме?**

**-** Кече улым Айнар хәзер 4 сыйныфта белем ала һәм бию, баян, хоккей түгәрәкләренә йөри.

**- Укытучыларга теләкләрегез...**

**-** Иң беренче чиратта, мин аларның барысына да сәламәтлек телим.







Җәмилова Айзилә

Халыкара олимпиада

# Халыкара олимпиада



Гимназия укучыларыбыз җәй көннәрен бушка уздырмады. 3-7 июнь көннәрендә хәзерге 9 нчы сыйныф укучылары Хәбирова Наилә, Низамова Сөмбел һәм Шәрифуллина Рузилә, рус теле укутучысы Ольга Сергеевна белән Казанга рус теленнән Халыкара олимпиадага барып кайттылар.

Алар анда укудан тыш Казан буенча төрле экскурсияләргә һәм музейларга бардылар. Мәсәлән, Казан шәһәре, Иске Татар бистәсе буенча сәяхәт, Казан Кремленда һәм Зөя утравындагы Дәүләт тарихи-архитеткура һәм сәнгать музеенда булдылар. Аларның әйтүе буенча, иң кызыгы К. Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театрында Илдар Юзеевның " Гашыйлар тавы" спектаклен карау булган.

- Рузилә, сиңа театрадан тыш, тагын нәрсә ошады?
- Миңа безнең бергә яшәвебез, бергә утырып эзерләнүебез бик ошады. Тагын бик күп бүләкләр һәм бик тәмле ашатулары. (көлә)
- Ә нинди бүләкләр бирделәр?
- Бик тәмле чәк-чәк, олимпиаданың эмблемасы-тәлинкә, блокнот белән ручка һәм бик уңайлы рюкзак.
- Ооо, шәп! Сөмбел, ә сиңа ничек олимпиада? Авыр булдымы?
- Олимпиада үзе алай авыр булмады. Бик дулкынландыргыч кына булды. Мин олимпиаданың телдән өлешеннән бик курыккан идем, ләкин мин үз-үземне кулга алдым һәм алар биргән бөтен сорауларга да җавап биреп, 50дән 35 балл җыйдым.

Безнең кызларыбызга призлы урынга бары 1-2 балл җитмәде, тик алар кайгырмады. Икенче елга тагын катнашып, 1нче урын алачакбыз, диделәр. Аларның сүзләре буенча, иң мөһиме - белемнәрен сынап карау, рәхәтләнеп күңел ачу һәм, җәйнең беренче көннәрен бергә үткәреп, Казанны күреп кайтудан туган позитив энергия.

*Хәбирова Наилә*

# Сәләт-мәхәббәт

Сәләт" кебек оешма турында сезгә еш ишетергә туры килгәндер. "Сәләт" нәрсә соң ул? Сәләт - Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләренең интеллектуаль иҗат потенциалын ачу һәм үстерү берләшмәсе. «Сәләт» Идел буена кергән регионнарда (Башкортстан, Самара өлкәсе, Татарстан, Чуашстан) аланнарны, кышкы һәм җәйге махсус сессияләрне, тематик форум, җыр һәм кинематограф фестивальләрен, чит илләрдә исә («Сәләт-Прага», "Сәләт-Монреаль") халыкара мәктәп-аланнарын оештыра. Елдан-ел, катнашучыларның саны арта, чит төбәкләрдә



*Дәвамы киләсе биттә...*



“Сәләт” оешмасының үз максатлары һәм низамәтләре бар. Иң төп максатлар итеп, “Сәләт” оешмасы татар телен өйрәнү, әби-бабалардан калган гореф-гадәтләрне саклап калу кебек максатларга өстенлек бирә.



Үзенең 23 еллык тарихында Сәләт 120 меңнән артык сәләтле баланы, яшьләрне, укытучыларны берләштерде. Балаларны нәрсә шулай “Сәләт”кә тартып тора соң? “Сәләт”тәге кебек атмосфераны сез беркайда да очрата алмаячаксыз! Моннан тыш, балалар форумда төрле ярышларда катнашып, күңел ачып кына калмый, белем дә ала. Алар мантыйкка, информатикага да төшенә, кул эшләренә дә өйрәнә!

Безнең мәктәп укучылары да “Сәләт” сменаларында бик теләп катнашалар, аларның саны елдан-ел артып бара. Аларның уй-фикерләрен дә белешеп алыйк әле.

Низамова Сөмбел, 9 нчы сыйныф укучысы: ”Мин “Сәләт” белән 2014 елда якын таныштым, “Сәләт Биләр форумы”на кунак ролендә бардым. Аннан алдагы елларны апам “Сәләт” сменаларында актив катнашып, бик яратып, мактап кайтты. Иң зур ачышым буларак, “Сәләт”оешмасын саныйм.”

Афзалтдинова Гүзәл, 9 нчы сыйныф укучысы: “Мин беренче тапкыр 2015 елда “Сәләт-Болгар” аланына бардым. Андагы беренче кичерешләр әле һаман истә... (елмая) Безне ачык йөзле әйдаманнар каршы алды. Алар безгә бер минут та тик утырырга вакыт калдырмый иделәр. Күңелле чараларга, мастер-классларга кумәкләшеп йөри-йөри дуслашып беттек: безнең төркем иң шәбе, иң яхшысы кебек иде. Хәер, башкаларга да үз төркеме шулай тоелгандыр. Кыскасы, без бик дуслаштык... Вакыт тиз уза. Иялэшеп, дуслашып беттек дигәндә генә, смена азагы килеп җитте. Китәсе көнне, мөгаен, бар баланың да күзләрендә яшь күренгәндер. Чөнки китәсе килми иде! Кем яңа дуслар табарга, үзен башка яктан ачарга, җәй айларын кызыклы һәм файдалы уздырырга тели,”Сәләт”кә барырга киңәш итәм!”

Шәхсән мин, “Сәләт” белән 2016 елда гына таныштым. “Сәләт” лагере турында еш ишетергә туры килгән иде: узган ел анда булып кайткан дусларым мактап туймадылар. Мин дә барырга теләдем һәм... кызганмадым! Сөрәннәр, рәхәтләнеп биюләр, кызык уеннар белән көн артыннан көн үтте. Җәйнең эссе унике көне сизелмәде дә... Менә шулай... Сез дә кызыксындыгызмы, алайса киләсе елны “Сәләт”тә очрашыйк!










*Сәхәбетдинова Регина*

# Туган көн- гомер бәйрәме...



**1 нче сыйныф:**
**Логинова Карина 15.09**
**2 нче сыйныф:**
**Армянинов Ждан 21.09**
**Маннаев Тимур 15.09**
**3 нче сыйныф:**
**Мөбарәкҗанов Вилдан 02.09**
**Сафиуллина Сабрина 26.09**
**Степанова Елизавета 27.09**
**4 нче сыйныф:**
**Петров Рифат 17.09**
**Миннәхмәтова Ралина 18.09**
**Хаҗиев Данис 21.09**
**7 нче сыйныф:**
**Нуруллина Айсылу 14.09**
**Васильев Радмир 16.09**
**Иванов Владислав 21.09**



**8 нче сыйныф:**
**Маркова Луиза 28.09**
**9 нчы сыйныф:**
**Васильев Рунар 26.09**
**11 нче сыйныф:**
**Хаҗиев Динар 29.09**





**Баш мөхәррир** —Низамова Сөмбел
**Әдәби консультант-** Җәмилова Айзиля
**Бүлек мөхәррирләре** - Хәбирова Наилә
**Проект җитәкчеләре** — татар теле һәм әдәбияты укытучылары Ильина Миләүшә Әхтәм кызы, Заһриева Гөлнара Рөстәм кызы.

423700, ТР, Минзәлә шәһәре,
Чаллы тракты, 1А,
тел./факс (885555)3-51-71,
www.gimnazia-menz.edusite.ru
e-mail: sch1104_tg@mail.ru
Instagram: @gimnaziya__official
http://vk.com/id324010745